РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

БАШКАРМА КОМИТЕТ
ГОРОДА АЗНАКАЕВО
АЗНАКАЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

АЗНАКАЙ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ
АЗНАКАЙ ШӘҺӘРЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Ленин ур., 14 йорт, Азнакай шәһәре, 423330 Ленин урамы, 14 йорт, Азнакай шәһәре, 423330

Тел./факс(885592)7-15-50, 7-00-37; E-mail:aznakay@tatar.ru кат adm-aznakay@mail.ru;
http://aznakayevo.tatarstan.ru/

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

«15» декабрь 2011 ел № 38

Азнакай шәһәре башкарма комитетының
2009 елның 26 февралендәге 05 нче номерлы
"Муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ
Регламенты турында” карарына үзгәрешләре кертү
хакында (05.08.2019 № 26, 11.11.2019 № 36,
24.04.2020 № 14, 14.09.2020 № 24,
28.07.2021 № 23, 21.09.2021 № 29
24.04.2020 № 14, 14.09.2020 № 24,
28.07.2021 , № 23, 21.09.2021, № 29 карарлар редакциясендә)

2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2021 елның 13 апрелендәге 242 номерлы «Татарстан Республикасы дәүләт учреждениеләре күрсәтә торган, дәүләт йөкләмәсе (заказ) урнаштырыла торган социаль әһәмиятле дәүләт хезмәтләрен, хезмәт күрсәтүләрен электрон формада күрсәтүгә күчү чаралары планын раслау турында» карары нигезендә карар итә:

1. Азнакай шәһәре башкарма комитетының 2019 елның 26 февралендәге 05 нче номерлы «Муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентлары турында» карарына (05.08.2019 № 26, 11.2019 № 36, 24.04.2020 № 14, 14.09.2020 № 24, 28.07.2021 № 23, 21.09.2021 № 29 карарлар редакциясендә ) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.2. "Муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты муниципаль торак фондының социаль наем шартнамәсе буенча бирелгән торак урыннарын алмаштыру буенча документларны рәсмиләштерү буенча» 5 нче кушымтаны, әлеге карарга 1 нче кушымта нигезендә яңа редакциядә бәян итәргә.

1.3. «Муниципаль торак фондының торак урыннарын гражданнар милкенә тапшырганда документларны рәсмиләштерү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты" 6 нчы кушымтаны, әлеге карарга 2 нче кушымта нигезендә яңа редакциядә бәян итәргә.

1.4. "Элек хосусыйлаштырылган торак биналарны муниципаль милеккә кабул итү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты" 7 нче кушымтаны, әлеге карарга 3 нче кушымта нигезендә яңа редакциядә бәян итәргә.

1.5. «Муниципаль торак фондында гражданнарга хезмәт урыны наем шартнамәләре буенча торак урыннары бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты» 8 нче кушымтаны, әлеге карарга 4 нче кушымта нигезендә яңа редакциядә бәян итәргә.

1.6. «Җирле әһәмияттәге автомобиль юлларыннан файдаланучыларга автомобиль юлларының торышы турында мәгълүмат бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты" 10 нчы кушымтаны 5 нче кушымта нигезендә яңа редакциядә бәян итәргә.

1.7. "Муниципаль милектәге җирләрдә, аукцион үткәрмичә, стационар булмаган сәүдә объектларын урнаштыру өчен шартнамә төзү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты" 11 нче кушымтаны, әлеге карарның 6 нчы кушымтасы нигезендә яңа редакциядә бәян итәргә.

1.8. Расларга:

- әлеге карарга 7 нче кушымта нигезендә, «Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының «Азнакай шәһәре» муниципаль берәмлегенең махсуслаштырылган торак фонды составына һәм составыннан төшереп калдыру буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын» .

- Әлеге карарга 8 нче кушымта нигезендә «Юл билгеләрендә индивидуаль проектлауның мәгълүмати билгеләрен урнаштыру буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын».

2. Әлеге карарны "Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында" түбәндәге веб-адрес буенча бастырып чыгарырга: http://pravo.tatarstan.ru һәм Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында «Интернет» мәгълүмати-коммуникацион челтәрендә түбәндәге веб-адрес буенча урнаштырырга: http://aznakaevo.tatar.ru//.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Җитәкче Э.Ә. Габдрахманов